

Китапнын тормыштагы урыны турында кvп сойләргә була. Китап укырга соючеләрнен грамоталылыгы арта, тарих, әдәбият, мәдәният турындагы белемнәре кинәя, әлегә билгеле булмаган жирләр белән таныша...
Тапталган сvзләр, әмма бик тирән мәгънә салынган аларга. Боек Тукай да: «...Шул вакытта мин кулыма китап алам», - дигән бит. Китап яшәргә, фикер йортергә ойрәтә, кыскасы, суы кимемәс рухи чишмә ул. Шулай, Кадошкино китапханәсендә туган телгә, китапка багышлап торле кvргәзмәләр оештырыла, чаралар vтә.       - Бала чактан башлап гомерем буе китап укыйм. Сердәшем дә, кинәшчем дә, рухи таянычым да ул. Башта укытучы, аннары китапханәче хезмәтен дә юкка гына сайламаганмындыр. Кулга яна китап алгач, аны ачып укыр алдыннан була торган гажәеп рәхәт мизгелләр китапханәче хезмәтенен ин татлы, ин бәхетле минутларыдыр, могаен. Китапханәбезнен китап фонды бай. Шунын остенә кондәлек матбугат - газета-журналлар кvпме тагын. Рәхәтләнеп укы, кvнел байлыгы тупла. Борынгылар: «Беләге кочле - берне егар, белеме тирән - менне егар», - дип юкка гына әйтмәгәннәр, - дип сойләп китте Кадошкино районы китапханәсенен яшь хезмәткәре Динара Идрис кызы Альмяшева (рәсемдә сулдан беренче).
Китапханәгез турында берничә сvз әйтегез дигәнгә ул:
- Китапханәбез - заман таләпләренә туры китереп янартылган бинада. Компьютерларыбыз бар. Алар интернетка тоташтырылган. Кызыклы материалны кvчереп алырга теләгән кешегә шунда ук ксерокс тора. Болар барысы да кирәк, барысы да заманча. Ләкин китап укучылар белән очрашып, хәл-әхвәл сорашып, балаларнын шигырь укуларын тынлау - vзе бер жан рәхәте. Олылар белән кvрешеп сойләшкәч, кvнел бушатасын; кайчакларда гыйбрәт аласын, кинәшләргә колак саласын. Бvген кешеләргә әнә шундый аралашу житми, ә безнен китапханәдәге очрашулар шул бушлыкны тутыра. Кыскасы, хезмәтемне яратып башкарам.

**Наилә НАСЫРОВА**